ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-24-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Постановление
“22 ” декабрь 2017 ел

Карар
№ 25

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере үрнәген раслау турында

Эш башкаруны тәртипкә салу, Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты документларын ышанычлы тәнгәлләштерүне тәэмин итү максатларында, Мамадыш районы прокурорының дәүләт символлары турындагы закон бозуларны бетерү турындагы 15 августындагы № 02-08-03-2017 тәкъдиме, Мамадыш муниципаль районы Советының 2017 елның 13 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге гербын куллану турында» № 6-19 карары нигезендә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискын расларга.(1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 22 декабрендәге 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә мөһерләрне һәм штампларны исәпкә алу, әзерләү, куллану, саклау һәм юк итү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- мөһерләрне, штампларны һәм фирма бланкларын куллану;
- аларны куллануны, тиешле саклауны һәм саклануын контрольдә тоту.

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә..

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе /И.Я.Хаев/

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы гербы күчермәсе белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетының герб мөһере оттискы